

Туган як табигате - чиста һава һәм экологик яктан чиста ашамлыклар гына дигән сvз тvгел әле ул. Ул - Туган илебезнен матурлыгы да, жаны да.
Туган илебезнен чиста сулы елга һәм кvлләрен пычрату, очсыз-кырыйсыз урманнарны бер мәгънәсез кисеп бетерv, химия заводларынын агулы газлары белән чиста һавабызны бозып бетерv - болар әле хәзерге цивилизациянен туган ягыбыз табигатенә салган зыянынын бер олеше генә. Табигатьне пычратучылар белән корәшне без бvгеннән vк башламасак, берничә дистә елдан сон, ботен тереклек коеп беткән чvл уртасында калуыбыз бар бит.       Мәсәлән, Хаджи авылында гомер итvче Айса Низаметдин улы Карабанов болай искә тошереп сойли:
- Минем алтмышынчы елгы тулы сулы Инсар елгасыннан, без Зара дип йортәбез, чиста булганга, чәйгә су алуыбыз исемдә. Суга керсән, аягына балыклар бәрелеп торды шул вакытлар. Бу еллар минем яшvсмер чакларыма туры килә, шул вакыт иптәшләрем белән бергә колхоз котvен коттем. Ял иткәндә рәхәтләнеп Зарабызда балык тоттык; ойгә байтак китерә идек. Чиста суда гына яшәгән кысла-ракларны тотарга йордек. Инсар елгасы янында кvп кеше ял итәргә яратты; су кыена идек, кояшта кызындык, балык тоттык. Әмма бар әйбер vзгәрә. Суыбыз, бәлкем шәһәр заводлары продукциясе калдыклары гаепледер, пычранды. Инсар елгасы суын эчv тvгел, бакча яшелчәләрен кыярга да яравы шикле. Балык иске елга юлына китте. Мин vзем дә кvптән тvгел иске vзәннән 5 килолы чуртан-щука тоттым. Сонгы вакытта, бәлкем малёклар жибәргәдер, Инсар елгасында да карп кvренгәли башлады. Шатлыклы кvренеш, мондый елганы югалтасы килми.
Ә Ләмберәнен Лесная урамы (Урманлы) халкы ял итv мәйданындагы «Байкал» дип йорткән кvлләрен тозекләндерәләр. Ял итv очен шартлар тудыралар. «Байкал» дип Ләмбирә Урманлы урамы халкы атый. Аны Сибирьнен Байкалында вафат булган урамдашлары истәлегенә атаганнар. Чиста тирән сулы Байкалга тими инде бу кvлчек, әмма анын тирәсендә ял итvче хатын-кыз, балалары белән, башка урам кунаклары байтак. Тәртипсез ял итvчеләр артыннан шешә, кирәкмәгән кәгазь, аш калдыклары, пакетларны жыеп килә иде бу урам халкы. Тәртипсезлекне бетерvдә кvп коч Наиль Нарбеков, Зельфрид Хамидуллов, Николай Ежов һәм башка Урманлы урамы халкы куйды. Оч ел алдан кvл тирәсендәге кирәксез дип тапкан куакларны кисеп алдылар, vз акчаларына щебенка һәм песок алып сукмаклар ясадылар. Ике кәнәфи-беседка да булдырдылар. Пляж ясадылар. Сайлыкта балалар су коенса, алты метр тирәнлектә зурлар йозә ала. «Байкал»  тирәсендәге куаклыкта гомбәләр vсә башлады, чикләвек

куакларында уныш кvренде. Карась белән карп жибәрделәр кvлгә. Бар урам халкы комбикорм белән ашата аларны. Браконьерлардан видеокамера урнаштырдылар. Янадан кvл тирәсе пычрак базга әйләнмәсен очен, «Ремондис»контейнерлары да калкып чыкты. Хәзер читтән килеп ял итvчеләр генә тәртипсезләнмәсеннәр дигән теләк бар.  «Байкал» кvле матур ял урыны буларак озак яшәсен, Хаджи авылында гомер итvче Айса Низаметдин улы Карабанов истәлегендәге Исса елгасына әйләнмәсен иде.
Бу барысы да безнен Туган илебезнен матурлыгы да, жаны да. Димәк, табигатебез гvзәл һәм чиста булсын очен, урманнарны сакларга, кош ояларын туздырмаска, елга буйларын пычратмаска кирәк. Табигатьне кечкенәдән vк ярата, анын матурлыгын тоя, кvрә белгән кеше беркайчан да каты бәгырьле була алмый; бары тик әхлаклы, намуслы, чын кеше генә була ала.

**Н.Хәлил**